ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**16.03.2020**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 502**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Икътисадый совет төзү турында

Зеленодольск муниципаль районы икътисадының реаль секторы предприятиеләре һәм оешмалары эшчәнлеген, социаль өлкәне, халыкның икътисадый актив өлешен эш белән тәэмин итүне анализлау буенча чаралар комплексын эшләү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Икътисадый совет төзергә.
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Икътисадый советның кушымтада бирелгән составын расларга (1 нче кушымта).
3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Икътисадый совет турында Нигезләмәне расларга(2 нче кушымта)
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Җитәкченең беренче урынбасары А. В. Старостин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
1 нче кушымта
16.03.2020 № 502

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башкарма комитетының Икътисадый совет составы**

| | |
|---|---|
| Афанасьев Михаил Павлович | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе,<br>Икътисадый совет рәисе |
| Усманов Марат Зәкәри улы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, Икътисадый совет рәисе урынбасары |
| Хәбибуллин Зөлфәт Флүн улы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары,<br>Икътисадй совет рәисе урынбасары |
| Стерякова Анастасия Сергеевна | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-икътисадый фаразлау һәм анализлау бүлеге башлыгы,<br>Икътисадый совет секретаре |
| Кадникова Эльза Ренат кызы | Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Хисаметдинов Рөстәм Рәшит улы | Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Дёгтева Ольга Павловна | «Зеленодольск муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МУ җитәкчесе |
| Алексахина Анна Юрьевна | «Зеленодольск муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МУ җитәкчесе |
| Путин Алексей Евгеньевич | Россия Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 8 нче номерлы районара инспекциясе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Җиһаншин Таһир Галимҗан улы | «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе» МУ начальнигы(килешү буенча) |
| Гататдинова Светлана Владимировна | «Зеленодольск шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры (килешү буенча) |
| Антонова Мария Михайловна | «Зеленый дол «Инвестиция үзәге» ЗМР автоном учреждениесе җитәкчесе |
| Шакиров Марат Госман улы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Куллапучылар базары бүлеге начальнигы |

| | |
|---|---|
| Мистахов<br>Ренат Искәндәр улы | «Ак Барс» суднолар төзү корпорациясе » АҖ генераль директоры (килешү буенча) |
| Карпов<br>Александр Николаевич | «Горький исемендәге завод» АҖ генераль директоры (килешү буенча) |
| Хәсәнов<br>Радик Шәүкәт улы | «Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе» АҖ генераль директоры (килешү буенча) |
| Егоров<br>Эдуард Юрьевич | «Идел буе фанер-мебель комбинаты » ҖЧҖ генераль директоры (килешү буенча) |
| Галиев<br>Әүфәр Зөфәр улы | «Зеленодольск сөт эшкәртү комбинаты» АҖ техник директоры (килешү буенча) |
| Жирков<br>Евгений Николаевич | «Зеленодольск проект-конструкторлык бюросы»АҖ генераль директоры (килешү буенча) |
| Ганиев<br>Илшат Газыйм улы | «Майский» ТК» ҖЧҖ директоры, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты (килешү буенча) |
| Тимергалиева<br>Рүзилә Равил кызы | эшмәкәр, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты (килешү буенча) |
| Грузков<br>Дмитрий Вячеславович | «Основа» ҖЧҖ генераль директоры (килешү буенча) |
| Фазулов<br>Азат Ревгат улы | «КЗПА » ҖЧҖ генераль директоры (килешү буенча) |
| Бригаднов<br>Валерий Викторович | «М7 индустриаль паркы» ҖЧҖ директоры (килешү буенча) |
| Антипов<br>Сергей Константинович | Зеленодольск муниципаль районы предприятиеләре һәм оешмаларының профсоюз комитетлары рәисләренең координацион советы рәисе(килешү буенча) |
| Кашапов<br>Айдар Салих улы | «Зеленодольскгаз» эксплуатация-җитештерү идарәсе начальнигы (килешү буенча) |
| Гордеева<br>Лариса Викторовна | «Зеленодольск икмәк комбинаты» ЗАҖ генераль директоры (килешү буенча) |
| Андреев<br>Сергей Павлович | «Ак Барс «Кошчылык комплексы » ҖЧҖ генераль директоры (килешү буенча) |
| Разов<br>Илназ Илфат улы | Зеленодольск районы электр челтәрләре начальнигы (килешү буенча) |
| Савельев<br>Сергей Николаевич | «Табигать бүләкләре» АҖ директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Садыйков Рамил Әмир улы | «Зеленодольск пассажир автотранспорт предприятиесе» ҖЧҖ, «Экспресс " ҖЧҖ директоры (килешү буенча) |
| Муханов Виктор Семенович | «Зеленодольск механика көллияте» ДАҺБУ директоры (килешү буенча) |

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
2 нче кушымта
16.03.2020 № 502

**Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисадый советы турында НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисадый советы (алга таба - Икътисадый совет) Зеленодольск муниципаль районы предприятиеләре һәм оешмалары эшчәнлеген тотрыклыландыру, финанс-кредит секторын савыктыру, халыкка социаль һәм икътисадый ярдәм күрсәтү чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру белән бәйле мәсьәләләрне оператив хәл итү максатыннан оештырылган киңәшмә органы булып тора.

2. Икътисадый совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты һәм Татарстан Республикасы Президенты Указларына һәм күрсәтмәләренә, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына, Зеленодольск муниципаль районының норматив-хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Икътисадый советның төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

- социаль-икътисадый өлкәдә кризис күренешләрен булдырмау, аның алга таба үсешен һәм тотрыклылыгын тәэмин итү механизмнарын эшләү һәм тормышка ашыру;

-Сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләре, Зеленодольск муниципаль районы икътисадының реаль секторындагы башка оешмалар эшчәнлеген тотрыкландыру, финанс-кредит секторын савыктыру, халыкка социаль һәм икътисадый ярдәм күрсәтү чараларын тормышка ашыруга даими мониторинг ;

4. Икътисадый совет үзенең төп бурычларын үтәү өчен түбәндәгеләргә хокуклы:

- җирле үзидарә органнарыннан, дәүләт һәм федераль хакимият органнарыннан, иҗтимагый берләшмәләрдән, предприятиеләр һәм оешмалардан, фәнни һәм башка оешмалардан, шулай ук вазыйфаи затлардан тиешле тәртиптә кирәкле материалларны соратып алдырырга һәм алырга;

- үз утырышларына җирле үзидарә органнарының, дәүләт һәм федераль хакимият органнарының вазыйфаи затларын, иҗтимагый берләшмәләрнең, фәнни һәм башка оешмаларның вәкилләрен чакырырга;

- мәгълүмати-аналитик һәм эксперт эшләрен гамәлгә ашыру өчен фәнни һәм башка оешмаларны билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә.

5. Икътисадый совет составына Икътисадый совет рәисе, аның урынбасары, секретаре һәм Икътисадый совет әгъзалары керә. Икътисадый совет әгъзалары аның эшендә җәмәгать башлангычларында катнаша.

6. Икътисадый совет утырышлары кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла. Кирәк булган очракта Икътисадый советның чираттан тыш утырышлары үткәрелергә мөмкин. Икътисадый совет утырышларын әзерләүне һәм үткәрүне Икътисадый совет секретаре гамәлгә ашыра.

7. Икътисадый совет утырышын Икътисадый совет рәисе йә аның урынбасары алып бара.

Икътисадый совет карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа Икътисадый совет рәисе, йә Икътисадый совет утырышында рәислек итүче зат кул куя.

Икътисадый совет карарларын тормышка ашыру өчен Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарлары һәм боерыклары чыгарылырга мөмкин.

8. Икътисадый совет карарлары үтәлешен Зеленодольск муниципаль районының структур бүлекчәләре үз вәкаләтләре нигезендә тикшереп тора.

9. Икътисадый совет үзенә йөкләнгән төп бурычлар нигезендә Икътисадый совет әгъзалары арасыннан, шулай ук Татарстан Республикасы Башкарма хакимияте органнарының башка вәкилләре арасыннан үз эшчәнлеге юнәлешләре буенча ведомствоара эшче төркемнәр төзи ала. Төзелә торган эшче төркемнәр белән җитәкчелек итү Икътисадый совет әгъзаларына йөкләнә.